| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |
| --- | --- |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.09.2015 г.Казань № 225/2-пр

Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы оешмаларына “орлыкчылык хуҗалыгы” статусын бирү турында

“Орлыкчылык турында” 1997 елның 17 декабрендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре” 2005 елның 6 июлендәге 316 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы турында нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.3 пунктын үтәү өчен

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының игенчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы В.Л. Новичковка Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы оешмаларына I яки II категорияле “орлыкчылык хуҗалыгы” статусын бирү буенча эшне оештырырга.

2. Расларга:

2.1. Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы оешмаларына I яки II категорияле “орлыкчылык хуҗалыгы” статусын бирү турында нигезләмәне боерыкка 1 нче кушымта нигезендә;

2.2. I яки II категорияле “орлыкчылык хуҗалыгы” статусын бирү турында гариза формасын боерыкка 2 нче кушымта нигезендә;

2.3. Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы оешмаларына I яки II категорияле “орлыкчылык хуҗалыгы” статусын бирү буенча республика комиссиясе составын боерыкка 3 нче кушымта нигезендә;

2.4. Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы оешмаларына I яки II категорияле “орлыкчылык хуҗалыгы” статусын бирү буенча эшче төркем составын боерыкка 4 нче кушымта нигезендә;

2.5. Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы оешмаларына I яки II категорияле “орлыкчылык хуҗалыгы” статусын бирү буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында орлыкчылык торышына бәя бирү акты формасын боерыкка 5 нче кушымта нигезендә.

3. Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы Ә.Ә. Закировка Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарына әлеге боерыкны гамәлгә ашыру

максатларында баручы хезмәткәрләрнең командировка чыгымнарын түләүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары И.Х. Габдрахмановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

2015 елның 28 сентябрендәге 225-2/пр
номерлы
ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы оешмаларына**
**I яки II категорияле "орлыкчылык хуҗалыгы" статусын бирү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасында орлыкчылык системасын бөртекле, бөртекле-кузаклы культураларның һәм ярма культураларының югары сыйфатлы орлыкларын җитештерү һәм чәчү хисабына камилләштерү, Татарстан Республикасында орлыкчылыкны алга таба үстерүне стимуллаштыру, орлыкчылык өлкәсендә дәүләт ярдәме чараларының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында эшләнде.

Нигезләмә "Орлыкчылык турында" 1997 елның 17 декабрендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законга таянып язылды.

2. I яки II категорияле "орлыкчылык хуҗалыгы" статусы (алга таба – статус) Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы оешмаларына (алга таба – оешмалар) законнарда каралган дәүләт ярдәменең остәмә чараларына дәгъва итү мөмкинлеген бирә.

Орлыкчылык торышына бәя бирү әлеге боерыкка 5 нче кушымта нигезендә башкарыла.

Орлыкчылык торышына бәя бирү акты буенча 201 баллдан алып 250 баллга кадәр җыйган оешма I категориягә, 150 баллдан алып 200 баллга кадәр – II категориягә керә.

3. Статус бирү өчен календарь елның 15 октябреннән алып 31 октябренә кадәрге чорда Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) әлеге боерыкка 2 нче кушымтада каралган форма буенча гариза тапшырган оешмалар карала.

4. Эшче төркем календарь елның 1 ноябреннән алып 15 ноябренә кадәр, оешмаларның гаризаларына нигезләнеп, гариза бирүче оешмаларның урнашу урыннарына барып, аларның хуҗалыклары торышына комплекслы анализ ясый, ахырда орлыкчылык торышына бәя бирү акты төзелә.

5. Эшче төркем орлыкчылык торышына бәя бирү актын календарь елның 20 ноябреннән соңга калмыйча республика комиссиясенә карау өчен тапшыру йөкләмәсен ала.

6. Республика комиссиясе бәя бирү актларын 5 эш көне эчендә карый һәм беркетмәдә күрсәтелгән карау йомгакларын министрга карап тикшерү һәм статус бирү турында боерык чыгару өчен җибәрә.

Министр тарафыннан беркетмә каралау һәм статус бирү турында боерык чыгарылу өчен 3 эш көне бирелә. Боерык чыгарганда министр республика комиссиясе беркетмәсенә таянып эш итә.

7. Министрның статус бирү турындагы боерыгы “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасы Рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына кергән Министрлыкның рәсми сайтына куела.

8. Оешмаларга статус бирү буенча орлыкчылык торышына бәя бирү актын төзегәндә хисап елы уңышын алу өчен орлыкның күпме күләмдә сатылуы исәпкә алына (узган елның 1 июленнән алып агымдагы елның 1 июленә кадәр).

9. Статусны раслау һәр 3 ел саен кабат башкарыла (календарь елның 15 октябреннән алып 15 ноябренә кадәр).

10. Статус бирелгән очракта, бюджет ярдәме хуҗалыкның бөртекле, бортекле-кузаклы культуралар һәм ярма культуралары орлыклары җитештерелә торган бүлекчәсенә генә бирелә.

11. Куелган орлыкларның сыйфатына карата календарь елга икедән күбрәк рекламация алган орлыкчылык хуҗалыклары 1 елга, ә мондый хәл кабатланган очракта – 3 елга статустан мәхрүм ителә.

2015 елның 28 сентябрендәге
225-2/пр номерлы
ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры
М.Г. Әхмәтовка

___________________________________
(гариза бирүченең ФИАи)

ГАРИЗА

Мин, ________________________________________________________________,
(ФИАи)

Сездән Нигезләмәдә каралган тәртиптә «орлыкчылык хуҗалыгы» статусын бирүне сорыйм.

_____________ _______________ «____» _________, 2015 ел
(имза) (ФИАи) Дата

М.У. (булган очракта)

2015 елның 28 сентябрендәге
225-2/пр номерлы
ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы оешмаларына I яки II категорияле “орлыкчылык хуҗалыгы” статусын бирү буенча республика комиссиясе составы**

| № т/б | ФИАи | Оешма исеме | Вазыйфа |
|---|---|---|---|
| Комиссия рәисе: | | | |
| 1 | И.Х. Габдрахманов | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Министр урынбасары |
| 2 | Р.К. Зиннәтуллин (комиссия секретаре) | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Орлыкчылык һәм химияләштерү секторының әйдәүче киңәшчесе |
| Комиссия әгъзалары: | | | |
| 3 | В.Л. Новичков | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Игенчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы |
| 4 | Д.А. Яшин | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Орлыкчылык һәм химияләштерү секторы мөдире |
| 5 | Ф.Г. Зиннәтов | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Бөртекле һәм техник культуралар секторының әйдәүче киңәшчесе |
| 6 | М.Ш. Таһиров | Россия авыл хуҗалыгы академиясенең Татарстан Фәнни-тикшеренү институты дәүләт фәнни учреждениесе | Директор (килешү буенча) |
| 7 | Ю.В. Ером | Эшен үзе җайга салучы “Татарстанның элиталы өрлыклары” ассоциациясе | Директор (килешү буенча) |
| 8 | В.В. Минһаҗев | “Россия авыл хуҗалыгы үзәге” федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы | Җитәкче (килешү буенча) |
| 9 | С.Л. Турнин | “Селекция казанышларын сынау һәм саклау буенча дәүләт комиссиясе” федераль дәүләт бюджет учреждениесе филиалы | Башлык (килешү буенча) |

2015 елның 28 сентябрендәге
225-2/пр номерлы
ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-
төлек министрлыгы боерыгына
4 нче кушымта

**Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы оешмаларына I яки II категорияле “орлыкчылык хуҗалыгы” статусын бирү буенча эшче төркем составы**

| № т/б | ФИАи | Оешма исеме | Вазыйфа |
|---|---|---|---|
| Эшче төркем җитәкчесе: | | | |
| 1 | В.Л. Новичков | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Игенчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы |
| Эшче төркем әгъзалары: | | | |
| 2 | Д.А. Яшин | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Орлыкчылык һәм химияләштерү секторы мөдире |
| 3 | Р.К. Зиннәтуллин | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Орлыкчылык һәм химияләштерү секторының әйдәүче киңәшчесе |
| 4 | Ф.Г. Зиннәтов | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Бөртекле һәм техник культуралар секторының әйдәүче киңәшчесе |
| 5 | М.А. Кашапов<br>В.Н. Егоров<br>Ш.А. Зәйнуллин | Эшен үзе җайга салучы “Татарстанның элиталы орлыклары” ассоциациясе | (килешү буенча) |
| 6 | Р.Р. Хәбибуллин<br>Е.В. Яркәева | “Россия авыл хуҗалыгы үзәге” федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы | (килешү буенча) |
| 7 | Штат буенча | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе | Игенчелек буенча консультант (килешү буенча) |

2015 елның 28 сентябрендәге 225-2/пр номерлы
ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
5 нче кушымта

**Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы оешмаларына I яки II категорияле "орлыкчылык хуҗалыгы" статусын бирү буенча Татарстан Республикасы _______________________ муниципаль районының ___________________________ орлыкчылыгы торышына бәя бирү акты**

| № т/б | Күрсәткечнең исеме | Балларда бәя | Факт буенча баллардагы бәя |
|---|---|---|---|
| 1 | **Югары квалификацияле кадрлар белән тәэмин ителеш** | | |
| | агроном юк | 0 | |
| | 1 агроном бар (хуҗалыкның сөрү җирләре мәйданы 2000 га кадәр) | 2 | |
| | 2 агроном бар (хуҗалыкның сөрү җирләре мәйданы 2000 га күбрәк) | 3 | |
| | 2 агроном бар, шул исәптән 1 орлыкчы | 5 | |
| | (шул исәптән эш тәҗрибәсе 5 елдан ким булган) | 8 | |
| | үрнәкләр алуга һәм чәчүлекләрне апробацияләргә аккредитацияләнгән белгечнең булуы | 5 | |
| | агрономия факультеты студенты бар хуҗалык стипендиаты | 2 | |
| | **Кадрлар буенча барлыгы:** | **0-15** | |
| 2 | **Орлыкларны сыйфатлы итеп әзерләүне тәэмин итә торган матди-техник базаның торышы** | | |
| | Орлыкларның кечкенә партияләрен беренчел һәм икенчел чистарту өчен үзкүчешле машиналарның булуы<br>шул исәптән орлык киптергечнең булуы | 3<br>5 | |
| | Бер орлык чистарту линиясе бар (орлык чистарту машиналарының тулы комплектын үз эченә ала: беренчел, икенчел һәм соңгы (триер) чистарту машиналары, орлык киптергеч) | 8 | |
| | Ике орлык чистарту линиясе бар, берсендә барлык машиналар да бар, икенчесендә - юк (орлык чистарту машиналарының тулы комплектын үз эченә ала: беренчел, икенчел һәм соңгы (триер) чистарту машиналары, орлык киптергеч) | 12 | |
| | Ике һәм аннан күбрәк орлык чистарту линиясе (орлык чистарту машиналарының тулы комплектын үз эченә ала: беренчел, икенчел һәм соңгы (триер) чистарту машиналары, орлык киптергеч) | 15 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Өргечле иләкле машиналар өчен иләкләрнең тулы комплекты булу<br>шул исәптән: | 3 | |
| | иләкләрнең номерлары һәм зурлыклары буенча аерып куелганнар | 2 | |
| **Орлыкларны хәзерләп куюның матди-техник базасы буенча барлыгы:** | | **0-20** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | **Орлыкларны саклауның техник базасы** | | |
| | Начар аерыла торган авыл хуҗалыгы культуралары аерым саклана торган ике һәм аннан күбрәк орлык склады бар | 10 | |
| | Складларда авыл хуҗалыгы культураларын сортлар һәм репродукцияләр буенча урнаштыру схемасы булу | 3 | |
| | Орлыкларның культурасы, сорты, репродукциясе, партиясе һәм чәчүлек сыйфатлары күрсәтелгән этикеткалары булу | 2 | |
| | Амбар корткычларының булмавы (кондиция турындагы таныклык, сынаулар беркетмәләре, сертификатлар белән раслана) | 2 | |
| | Орлыкларны һәм көлтәләрне келәт хезмәткәренә тапшыру акты булу | 2 | |
| | Челтәрсыман коймалар белән:<br>орлык складларының 50 проценты<br>орлык складларының 100 проценты җиһазланган | <br>2<br>3 | |
| | Орлыкларның бозылуын чикли торган җайланмаларның булуы (склад диварларыннан конденсат үтеп керүне булдырмый торган изоляция), шул исәптән:<br>орлык складларының 50 проценты<br>орлык складларының 100 проценты җиһазланган | <br><br><br>2<br>3 | |
| | **Орлыкларны саклау буенча барлыгы:** | **25** | |
| 4 | **Орлыкларны агулау техникасы** | | |
| | Эшләргә яраклы дип табылган агулау машиналарының булуы<br>- барлык культураларга да 1 машина | 3 | |
| | - культуралар төркемнәренә 2 һәм аннан күбрәк машина | 5 | |
| | - индивидуаль саклану чаралары белән тәэмин ителгән булу | 2 | |
| | - кулланылачак эремәне әзерләү өчен аерым савыт булу | 3 | |
| | **Орлыкларны агулау буенча барлыгы:** | **10** | |
| 5 | **Орлыкчылык хуҗалыгы өчен җиһазлар булу** | | |
| | Бар: агроном бүлмәсе | 3 | |
| | орлык үрнәкләрен алу өчен щуп | 2 | |
| | орлыктагы дымны үлчәгеч | 2 | |
| | термоштанга | 2 | |
| | 1 граммга кадәр төгәллек белән күрсәтүе тикшерелгән лаборатория үлчәве | 2 | |
| | сүтелә торган такта | 2 | |
| | лаборатория иләкләренең һәм лупаларның булуы | 2 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Җиһазлар буенча барлыгы:** | **15** | |
| 6 | **Агрономия документларын алып бару һәм бөртекле культураларның орлыкларын җитештерү** | | |
| | Басу-кырлар тарихының соңгы 3 елга тутырылган журналы булу | 2 | |
| | алып бару сыйфаты | 1-3 | |
| | җайга салынган чәчү әйләнеше, шул исәптән орлык чәчү әйләнеше булу | 3 | |
| | читтән серкәләнә орган культуралар өчен пространство изоляциясе нормаларының үтәлүе | 5 | |
| | чәчү әйләнеше кырлары буенча культураларны урнаштыру карталары булу | 2 | |
| | утау эшләрен төрләренә һәм сортларына карап башкару | 5 | |
| | сезонлы (язгы-көзге) кыр эшләрен үткәрү эш планында барлык культуралар буенча орлыкларга ихтыяҗ һәм чәчү нормалары исәпләнү | 5 | |
| | хуҗалыкның орлыкчылык кишәрлекләренең сортлар һәм репродукцияләр буенча чәчү һәм җыю схемалары булу (агымдагы елга факт) | 5 | |
| | Югары репродукцияләрне (оригиналь, элита) чәчүгә туры килгән өлеш:<br>- 35 проценттан югарырак<br>- 25-35 процент<br>- 20-25 процент | <br><br>10<br>7<br>4 | |
| | Орлык басуында РСт (куплэп) чәчүлекләре 10 проценттан күбрәк булу | (-) 5 | |
| | Оригиналь орлыкларны үрчетү коэффициенты:<br>5 кадәр 0 балл:<br>5-6 1<br>6-7 2<br>7-8 3<br>8-9 4<br>10 күбрәк 5 балл | 5 | |
| | Перспективалы яңа сортларны сынау һәм бәяләү буенча үз делянкалары булу, яисә аларны үрчетү | 5 | |
| **Бөртекле культураларның орлыкларын җитештерү буенча барлыгы:** | | **50** | |
| 7 | **Орлыкчылык документациясен алып бару** | | |
| | Соңгы 3 ел өчен тутырылган, шнурланган Орлыкларның исәп кенәгәсе булу | 5 | |
| | Алып бару сыйфаты | 1-5 | |
| | шнурланган Орлыкларның исәп кенәгәсе булмау | (-)20 | |
| | Сортлар чәчүлекләрен апробацияләү һәм теркәү актлары | 4 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Сатып алынган орлыкларга яраклылык сертификатлары булу | 4 | |
| | Патентлы сортларга лиҷензия һәм сублиҷензия шартнамәләренең, патентсыз сортларга оригинатор белән килешү, әгәр сорт Дәүләт реестрына кертелмәгән булса, яңа сортны үрчетүгә оригинатор белән килешү булу | 4 | |
| | Автор хокуклары саклану (роялти түләү) | 2 | |
| | Орлыклар партияләреннән үрнәкләр алу актлары | 4 | |
| | Үз ихтыяҗлары өчен орлыкларны сынау беркетмәләре | 4 | |
| | Сорт алмаштыру һәм сорт яңарту планнары (план/факт) | 4 | |
| | Чәчелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларының күләме һәм сыйфаты турында хисап | 3 | |
| | Орлыкларга Дәүләт стандартлары яки алардан өземтә булу | 2 | |
| | Чәчүлекләрне апробаҷияләүгә һәм орлыкларны сертификатлаштыруга заявкалар бирү регламентларының үтәлүе | 5 | |
| | бортекле, бөртекле-кузаклы культураларның һәм ярма культураларының орлыкларын җитештерү һәм сату планы булу | 4 | |
| | **Документация буенча барлыгы:** | **50** | |
| 8 | **Орлыкларны җитештергәндә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты** | | |
| | Районлаштырылган һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгы буенча перспективалы сортлар исемлегенә кертелгән сортларны 80 процентка һәм аннан күбрәккә куллану | 10 | |
| | Дәүләт реестрына кертелгән яңа сортларны иң күбе 5 ел куллану һәм районлаштырылмаган сортларны бөртекле ашлык басуларының 50 процентында һәм күбрәгендә үрчетү | 15 | |
| | **Орлыкларны җитештергәндә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты буенча барлыгы** | **25** | |
| 9 | **Сатыла торган орлыкларның сыйфаты** | | |
| | 1000 орлыкның массасы оригинаторлар һәм (яки) сортларның авторлары, һәм (яки) Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тәкъдимнәренә туры килә | 3 | |
| | Фузариоз һәм гельминтоспариоз авырулары белән зарарлану дәрәҗәсе<br>- аз<br>- уртача<br>- көчле<br>фитоанализ юк | <br><br>10<br>5<br>0<br>(-10) | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Чәчелә һәм сатыла торган орлыкларның сыйфаты буенча барлыгы:** | | **10** | |
| 10 | **Орлыклар базарында 5 елдан артык эшләү** | **5** | |
| 11 | **Орлыкчылык хуҗалыгы селекционерларның һәм орлыкчыларның илкүләм берлеге әгъзасы булып тора** | **20** | |
| **Хуҗалык буенча барлык максималь балл :** | | **250*** | |

* 201-250 балл - I категорияле хуҗалык;
150-200 балл - II категорияле хуҗалык;
150 баллдан кимрәк – хуҗалыкка категория бирелми

**Бюджет ярдәме алу өчен өстәмә шарт:**

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Һәр елны яңадан карала | | |
| | - бөртекле, бөртекле-кузаклы культураларның һәм ярма культураларының орлыкларын сату<br>- терлекнең күплеге уртача республика күрсәткечләренә караганда 25 процентка арту | 3,0 ц/га<br>2,0 ц/га | |

Бәяләмә

Комиссия әлеге акт нигезендә _______ категория бирергә тәкъдим итә.
Эшче комиссия әгъзалары:

_____________ _____________________
(имза) (ФИАи)

_____________ _____________________
(имза) (ФИАи)

_____________ _____________________
(имза) (ФИАи)

_____________ _____________________
(имза) (ФИАи)

Акт белән таныштым:
Оешма җитәкчесе _________________ _________________________
(имза) (ФИАи)

Баш агроном _________________ _________________________
(имза) (ФИАи)

дата______________ мөһер (булган очракта)